МИНИСТЕРСТВО
ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

13.08.2021 Казан шәһәре № под-1040/21

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлары исемлеген раслау турында

Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 28.3 статьясындагы 2, 3 һәм 4 өлешләре нигезендә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 5.57 статьясында, 9.13 статьясында, 14.1 статьясының 2, 3 һәм 4 өлешләрендә, 18.19 статьясының 2 өлешендә, 19.4 статьясының 1 өлешендә, 19.4.1 статьясында, 19.5 статьясының 1 өлешендә, 19.6, 19.7, 19.20, 19.30 – 19.30.2 статьяларында каралган административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затларының кушымтада бирелгән исемлеген расларга.

2. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлары исемлеген раслау турында» 2019 елның 09 декабрендәге под-1809/19 номерлы боерыгын гамәлдән чыккан дип танырга.

3. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тотуны министр урынбасары – Мәгариф өлкәсендә күзәтчелек һәм контрольлек департаменты җитәкчесе Р.Г. Мөҗиповка йөкләргә.

Министр И.Г. Һадиуллин

Татарстан Республикасы
Мәгариф һәм фән
министрлыгының
13.08.2021 № под-1040/21
боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 5.57 статьясында, 9.13 статьясында, 14.1 статьясының 2, 3 һәм 4 өлешләрендә, 18.19 статьясының 2 өлешендә, 19.4 статьясының 1 өлешендә, 19.4.1 статьясында, 19.5 статьясының 1 өлешендә, 19.6, 19.7, 19.20, 19.30 – 19.30.2 статьяларында каралган административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлары исемлеге

1. Министр урынбасары – Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының Мәгариф өлкәсендә күзәтчелек һәм контрольлек департаменты җитәкчесе.
2. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының Мәгариф өлкәсендә күзәтчелек һәм контрольлек департаменты җитәкчесе урынбасары.
3. Контроль-күзәтчелек эшчәнлеге идарәсе җитәкчесе.
4. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының Мәгариф өлкәсендә күзәтчелек һәм контрольлек департаментының түбәндәге бүлекләре җитәкчеләре:

контроль-күзәтчелек эшчәнлеге идарәсенең мәгариф өлкәсендә дәүләт күзәтчелеге;

контроль-күзәтчелек эшчәнлеге идарәсенең белем бирү сыйфатын дәүләт контролендә тоту;

контроль-күзәтчелек эшчәнлеге идарәсенең белем бирү оешмаларын лицензия контролендә тоту;

белем бирү эшчәнлеген лицензияләү;

белем бирү эшчәнлегенә дәүләт аккредитациясе;

белем алу һәм (яки) квалификация турында документларны раслау;

хокукый җайга салу;

аналитика, мәгълүмат һәм оештыру ягыннан тәэмин итү.

5. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының Мәгариф өлкәсендә күзәтчелек һәм контрольлек департаментындагы түбәндәге бүлекләрнең әйдәп баручы киңәшчеләре, әйдәп баручы консультантлары, әйдәп баручы белгечләре:

контроль-күзәтчелек эшчәнлеге идарәсенең мәгариф өлкәсендә дәүләт күзәтчелеге;

контроль-күзәтчелек эшчәнлеге идарәсенең белем бирү сыйфатын дәүләт контролендә тоту;

контроль-күзәтчелек эшчәнлеге идарәсенең белем бирү оешмаларын лицензия контролендә тоту;

белем бирү эшчәнлеген лицензияләү;

белем бирү эшчәнлегенә дәүләт аккредитациясе;
белем алу һәм (яки) квалификация турында документларны раслау;
хокукый җайга салу;
аналитика, мәгълүмат һәм оештыру ягыннан тәэмин итү.